**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«27» 01 2023 ел Яр Чаллы ш. №253

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән һәм Иштирәк авыл җирлекләре территориясендә «Этилен 600» индустриаль паркы объектларын урнаштыру максатыннан, территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Биклән һәм Иштирәк авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән һәм Иштирәк авыл җирлекләре территориясендә «Этилен 600» индустриаль паркы объектларын урнаштыру максатыннан, территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин